**Гаянова Фәндәлия Гильмегали кызы,**
Татар Ямалы төп гомуми белем бирү мәктәбенең 1 кв.категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**“Зирәк-шоу” бәйгесе**

Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар!
“Салават күпере” –дип исемләнгән
Зирәк –шоу бәйгесен башлыйбыз.

“Салават күпере” җыры, (башкара -3 кыз)

**Алып баручы:**
Рәхим итегез,- дип дәшәбез
Бүген кем генә килсә дә,
Чөнки дуслар бу залга
Җыелдык без зур Шоуга.

Сезгә туган тел дәшә.
Әзерме Сез көрәшкә?
Бүген менә бу бәйгедә
Ике команда көрәшә.

Хәзер көчле алкышлар белән бүгенге бәйгедә катнашучы, алдагы ярышта җиңүче команда –----------- класс укучыларын чакырабыз.

Рәхим итегез!

Һәм бүген беренче тапкыр бәйгедә катнашучы -----------класс укучыларын чакырабыз.

Рәхим итегез!

Ә хәзер бүгенге бәйгене бәяләп баручы Хөкемдарларыбыз белән таныштырам:

Баш хөкемдар--- мәктәпнең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары , география укытучысы-Гильманова Илүзә Рәхим кызы;

Мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы ------------ кызы;

Тарих фәне укытучысы- Мусина Дилбәр Тимергаян кызы

Хөкемдарларга сүзебез шул

Гадел хөкем итегез.
Бәйгене башлап җибәрдек
Әйдә, рәхим итегез!

**1нче тур.Командалар сәламләве. Без булдырабыз!**

Сүзне бирәбез ------------- классның “ -------------------------------“ командасына.
Рәхим итегез!
Рәхмәт.
Ә хәзер сүз ---------- классның “--------------------------------“ командасына бирелә.
Рәхим итегез!
Рәхмәт.

1нче тур нәтиҗәләре белән таныштыру өчен сүзне бирәбез хөрмәтле хөкемдарларыбызга. Рәхим итегез!
Рәхмәт.

**Командаларга уңышлар теләп, 2 нче турны башлыйбыз.**

Җавап бирү түбәндәгечә була:
- Мин сорауны укып бетергәч кенә төймәләргә басабыз.Кайсы команда алдан төймәгә баса , шул җавап бирә.
- Уенны дәвам итәбез.
- 1нче сорау..............
- алга таба дәвам итәбез һ.Б
- 2нче турның соңгы соравы
- ГОМУМИ нәтиҗәләр белән таныштыру өчен сүзне янәдән хөкемдарларыбызга бирәбез.
- РӘХМӘТ.

**Уеныбызның 3 нче турына күчәбез.КАПИТАННАР ярышы.**
Капитаннар көч сынаша
Команда данын яклап.
Алар биргән һәр җавапны
Хөкемдар барыр санап.
----------------классның “----------------“командасы капитанына сораулар бирәм, рәхим итегез!
Рәхмәт, тулы җаваплар алынды.

Ә хәзер------------ классның “----------------------------“ командасы капитанына сораулар бирәм, рәхим итегез!

Рәхмәт .

Хөкемдарларыбыз ГОМУМИ нәтиҗәләр чыгарган арада җанатарлар арасында иң Зирәк укучыларны билгелибез:

1нче сорау....Һ.б

(кызлар бирә)

Җиңүче билгеләнә, КУБОК бирелә.

Хөрмәтле Бәйгедә катнашучы укучыларыбыз!Бүгенге ярышта катнашып, СЕЗ зур гамәл башкардыгыз.Һәм сез барыгыз да җиңүчеләр!

Рәхмәт СЕЗГӘ!

Изгелекнең кайсын теләсәк тә
Аз булыр күк сезнең хөрмәткә.
Аяз көннәр, тыныч көннәр теләп,
Без калабыз изге теләктә.

Татар халкы өчен Тукайның “Туган тел” җыры инде милли гимнга әйләнеп бара.Бүгенге бәйгене шушы җыр белән тәмамласак,Зирәк-шоу безнең күңелләрдә матур истәлек булып сакланыр.

## ӘДӘБИЯТ БУЕНЧА СОРАУЛАР

1. *Гыйззәтем син, кадерем син,*
*Минем йөрәк бәгърем син:*
*Куанычым, шатлыгым*
*Тик син минем, синсең, син.*

Шигырьнең исеме, авторы.

**( Габдулла Тукай “ Бишек җыры “ )**

2. *Мәктәп директоры хатыны,(үзе укытучы кеше), коллегасы бозга таеп егылганда,”интеллигентно” күренергә тырышып: “Сез бик грандиозно егылдыгыз!”-ди.”Грациозно” дигән сүзне әйтүе кыен булган. Кайсы әсәрдән алынган өзек һәм авторы кем?*

**( Мөхәммәт Мәһдиев “ Фронтовиклар “ )**

3. *“Халыкка икмәк – тоз күрсәтмәгән кешенең үлгәч тә исемен телгә алмаслар. Тереклеге белән сөендермәгән кешенең үлеменә дә бик кайгырмаслар.”* Кем сүзләре?

***( Каюм Насыйри )***

4. *“Минем Хөршитбану исемле туган апам бар, әгәр ул исән булса, саклык кенәгәсендә акча булган сурәттә, аңа өч мең сум күләмдә ярдәм күрсәтсәгез яхшы булыр иде.” Кайсы әдипнең васыятнамәсеннән?*

**( Шәйхи Маннур )**

5. *Татарстанда беренче мәдрәсә ничәнче елда, кайда, кем тарафыннан ачыла?*

**( 1990 елда Чистай шәһәрендә Габделхак хәзрәт Саматов тарафыннан ачыла )**

6. *К. Насыйри халыкка сабак бирүнең, белем – мәгърифәт таратуның бер ысулын таба. Ул да булса – еллык өстәл календаре чыгару. Аның беренче һәм соңгысы ничәнче елда дөнья күрә?*

**( Беренчесе – 1870 , соңгысы – 1896 )**

7. *“Бертуктаусыз чылтырап чишмә ага. Чишмә суларына кушылып, минутлар ага. Әллә чишмәдән, әллә шушы кичтә генә ачылган хәлләрдән йөрәккә ниндидер өшеткеч һәм чиркандыргыч тамчылар сибелә.” Өзек нинди әсәрдән, авторы кем?*

**( Әхсән Баянов “ Тау ягы “ повесте)**

8. *Гамил Афзал бу сүзләрне кем турында язган? “Мин Сезне 20 ел укыйм. Пьесаларыгызны сәхнәгә куйдым, үзем уйнап йөрдем. Сурәтегезне*

*күргәнем юк, биографиягезне белмим. Ә йөрәгегезне тотып карагандай булам, хөрмәт итәм".*

**( Мирсәй Әмир турында 1956 елда )**

9. *Кем сүзләре?*
*Шунсыз җирдә яшәү мөмкин түгел,*
*Шунсыз булмас иде безгә сан-*
*Туган көннән үлгәнчегә кадәр*
*Кирәк, әни, хәер – фатихаң.*

**( Фәнис Яруллин " Әни, синең хәер – фатихаң")**

10. *1925 елда Мәскәүдә беренче театр мәктәбе ачыла. Булачак күренекле татар язучыларыннан кем шул мәктәптә укыган?*

**(Габдрахман Әпсәләмов )**

11.*Г. Камал театры артистлары "Агыйдел" җыр – бию ансамбле белән берлектә 1998 елда куйган " Галиябану" фильмы Актанышның кайсы авылында төшерелгән?*

**( Чиялек )**

12.*"Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул булыр", - дигән . Кем?*

**( Ризаэддин Фәхретдин)**

13.*"Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов" дигән картинаны кем эшләгән ?*

**( Башкорт рәссамы Мөхәммәт Усманов )**

14.*Балалар язучысы , хикәяче , тәрҗемәче , публицист , хатын-кыз язучыны атагыз* ?

**( Ләбибә Ихсанова )**

15. *Дәрдмәнд телне нәрсә белән чагыштыра* ?

**( Тел – илнең колагы )**

## Җанатарлар өчен сораулар

1. Кайсы очракта бер кулчатыр астында алты бала һәм ике көчек чыланмый кала ?

**( Яңгыр яумаганда )**

2. Бер йомгакта мең энә
Сиңа тими, син тимә

**( Керпе )**

3. Үлчәүсез йөртелә, һәркемдә була .

**( Акыл )**

4. Бу өч шәхесне нинди җепләр бәйли : А.С Пушкин, М.Җәлил, Латыйф Хәмиди

**( М.Җәлил Пушкинның " Чегәннәр " поэмасыннан бер өзекне тәрҗемә итә , шул өзеккә Латыйф Хәмиди романс яза )**

5. Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры сәхнәсендә зур уңыш белән барган " Татар хатыны ниләр күрми " , "Тирән тамырлар " әсәрен кем сәхнәләштергән ?

**( Татарстанның халык артисты Хәким Салимҗанов )**

6. Кайсы татар язучысы : " Тукай татар халкына поэзияне ачкан булса , Галимҗан Ибраһимов аның прозасын ачты" , - дигән.

**( Гомәр Бәширов )**

7. Нинди ояда беркайчан да йомырка булмый ?

**( Синонимнар оясында )**

8. Мәкальне дәвам ит.
Телеңне бәйдә тот ....

**( Этеңне бауда тот )**

9. Укый , яза белмәүче табиб.

**(Шаман )**

10. Бакый Урманче яратып башкара торган халык җыры.

**( “ Ашказар “ )**

11. Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосына язган операсы ничек атала ?

**( “Шагыйрь “ )**

12. Бу шигырьнең авторы кем ?

Укытучы апа сорый,
Ә без бирәбез җавап.
- Үскәч кем буласың килә ?
- Агроном,
-Врач,
- Солдат
Әйтә сүзен Җәүдәт тә :
- Пенсионер, әлбәттә

**( Әхсән Баянов, “ Җәүдәт сүзе “ )**

**КАПИТАННАР ӨЧЕН**
**ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР**

1. Бер телнең сузык авазлар системасын икенче төрле ничек атыйлар ?
**ВОКАЛИЗМ**
2. Хәрефләрне иң беренче булып кемнәр уйлап тапкан һәм кулланышка керткән ?
**Финикиялеләр**

3. Киттем дип китә, кире килә. Нәрсә ул ?
**Ишек**
4. Борынгы кешеләр хат язганда үзләренең уй- фикерләрен рәсемнәр аша аңлатырга тырышканнар. Әкренләп рәсемнәр шартлы билгеләр белән алмаштырылган. Бу нинди язу дип аталган һәм нәрсәне аңлаткан ? Бүгенге көндә кемнәр куллана ?
**Бу-идеографик язу. Идеограммалар бер фикерне , бер төшенчәне белдерәләр. Идеографик язу бүген япон, кытай язуларында сакланып калган**.

5.21 нче февраль нинди көн ?
**ЮНЕСКО карары буенча халыкара туган тел көне.**

6.Г. Ибраһимов татар революционеры Мулланур Вахитов белән беренче тапкыр кайда һәм кайчан очраша?
**1917 елның 21 июль – 2 августында Казанда уздырылган Бөтенроссия мөселманнарының II нче съездында**

7.“Яз башы” хикәясендәге Салих исемле унбер яшьлек шәкерт образының прототибы кем?
**( Г.Ибраһимов үзе )**

8.Г. Тукай премиясе лауреаты Х. Туфанның нинди шигыре Г. Ибраһимовка багышланган?
**( “Хатлар яза идек” ,“Сүнмәде дә, сүрелмәде дә “ )**

9. “Татарның үз театр бинасын күреп үлсәм, иң бәхетле үлем белән үлгән булыр идем.” Андый бәхеткә ирешә алмаган нинди артист сүзләре?
**( Габдулла Кариев )**

10.”Бердәмлектә - көч” дигән мәкаль туры килә торган әкият исеме ?
**( “Шалкан” әкияте )**

**КАПИТАННАР ӨЧЕН**
**ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР**

1.Өр-яңа савыт тишелеп беткән . Нәрсә ул ?
**( Иләк )**

2. Мәкальне дәвам итәргә .
**Гыйлем кош, ....**
**( Акыл канат)**

3.Үлчәүсез йөртелә, һәркемдә була.Ул нәрсә?
**(Акыл)**

4. Кайсы билгесезлек алмашлыгы уңнан да сулдан да бертөрле укыла?
**( Әллә )**

5. Армада, какао , кокос , серенада, томат сүзләре кайсы телдән кергән ?
**( Испан теленнән )**

6.“Дөньяда сүземез бар- үземез юк.” Кем сүзләре?
**( Акмулла )**

7. Казанны яулап алу” картинасының авторы кем?
**( Немец рәссамы Карл Вениг)**

8. Укый да , яза да белмәгән шагыйрь кем ?
**(Гомер)**

9. “Шәмсекамәр” драмасының авторы
**( Әблиев )**

10. Ничәнче елда , кайсы патша болгар татарларны ярты ел эчендә чукындырып бетерергә кушкан ?
**( 1713 елда , Петр -I )**

**ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА СОРАУЛАР**

1. Мәкальне дәвам итәргә:

Тамгаң ай , **ГАИЛӘҢ БАЙ** булсын .

2.Дәфтәр-кайсы халык сүзе, ул нәрсәне аңлата ?

**Грек сүзе.Борынгы греклар яза торган пергаментны яки махсус эшкәртелгән тирене дифтера дип атаганнар.Хәзерге заман дәфтәрләренең исеме шуннан килеп чыккан.**

3.Татар телендә беренче китап ничәнче елда һәм кайсы шәһәрдә басылган?

**1612 елда Лейпциг шәһәрендә**

4. Фигыль – термины каян килеп чыккан?

**“Фәгалә”- гарәпчә эш, хәрәкәт дигән сүздән**

5. Башка телләрдән кергән сүзләр- алынмалар телебездә бик күп. Парлары белән дә, сыңарлары белән дә үтеп кергәннәр. Турыдан – туры кергәннәре дә бер телдән икенчесенә күчә-күчә үтеп кергәннәре дә бар. Түбәндәге сүзләр нинди телләрдән кергән?

**Җәүһәр-гарәп**
**Гәүһәр –фарсы**
**Галош – немец**
**Калош- француз**
**Галстук – голланд**
**Галзтук - немец**

6. 18 нче апрель нинди көн ?

**Халыкара һәйкәлләр һәм тарихи урыннар көне.**

7. Пуризм нәрсә ул ?

**Телнең чисталыгы өчен көрәш**

8. Франциянең атаклы язучысы Анатоль Франс сүзлекләрне нәрсә дип атаган?

**Алфавит тәртибендә урнаштырылган галәм.**

9. Берничә телне өйрәнү – бер-ике еллык эш, үз телеңдә дөрес сөйләшергә өйрәнү өчен ярты гомер кирәк, - дип кем әйткән ?

**Вольтер**

10. Үзе дөнья буйлап йөри, ә үзе почмакка кереп поса. Нәрсә ул ?

**Конверттагы марка**

11. Субституция нәрсә ул ?

**Чит авазны кабул иткәндә, аны туган телдәге аваз белән алыштыру.(цыган – чегән)**

12.Тезаурус нәрсә ул ?

**Телдәге барлык сүзләрне җыйган сүзлекләр.**

13. Циркуль сүзенең искечә әйтелешен әйтегез.

**Җәзбә**

14. 1 нче апрель нинди көн ?

**1 нче апрель- юмор көне , алдау көне һәм Бөтендөнья кошлар көне.( 1906 елда кошларны саклау буенча Халыкара конвенциягә кул куелган .)**

15. Анаграмма нәрсә ул ?

**Сүзләрдәге хәрефләрнең ( яки иҗекләрнең ) урыннарын алыштырып , башка сүз ясау. ( мәсәлән : кайту-тукай)**